**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук кайбер затларның башка эшкә күчүләре һәм вазыйфалар атамалары үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы турында» 2015 елның 7 февралендәге ПУ-105 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы ПУ-365 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы турында нигезләмәдә:

16 һәм 17 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә ашыра.

17. Совет эшчәнлеген тәэмин итү, шул исәптән Совет утырышында катнашу өчен аның башка шәһәрләрдән килүче әгъзаларының юлга һәм торакка чыгымнарын, Совет тарафыннан оештырыла торган ведомствоара эш төркемнәре, вакытлыча оештырылган эш төркемнәре, төркемчәләр, советлар һәм эксперт комиссияләре әгъзалары һәм мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен башкару өчен җәлеп ителүче затларга тотылган чыгымнар Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәгариф һәм фән советы (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан Г.С. Дьяконовны чыгарырга;

Совет составына Юшко Сергей Владимировичны – Казан милли тикшеренү технология университеты ректоры вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча) кертергә;

Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

В.П. Ивановның – «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-производство берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) »;

С.А. Когогинның – «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Н.Ө. Мәгановның – В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 31 июль
№ ПУ-661